ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ  АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУТАЙ  АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2024 ел, 19 февраль №127

# Тутай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай  авыл җирлеге советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советының "Тутай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2021 елның 11 октябрендәге 38 нче номерлы карары белән расланган Тутай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) планлаштыру структурасы элементлары - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, гражданнарның бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе үз ихтыяҗлары өчен;»;

1.7 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) урам-юл челтәре элементлары - урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;".

2.Әлеге карарны а Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм җирлекнең мәгълүмат стендлары аша халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Тутай авыл җирлеге Башлыгы,
Тутай авыл җирлеге Советы рәисе Н.М.Насретдинова.